

Балтач бистәсендә бик матур, үрнәк, спорт сөючән гаилә яши. Ул –Ахметхановлар гаиләсе. Гаилә башлыгы Әхметханов Алмаз, Балтач сөт-май комбинатында зам. директор , ә тормыш иптәше Зөһрә Ривхатовна район башкарма комитеты ЗАГС бүлегендә эшли. Бу тату гаиләнең 2 баласы бар: Азамат –1 нче сыйныф укучысы, Зөһрә – 2 нче балалар бакчасына йөри.
Гаиләдә сәламәт яшәү һәм спорт белән шөгыльләнүгә зур игътибар бирәләр. Алар гаиләләре белән су коеныргa, велосипедта йөрергә, чаңгыда шуырга яраталар. Балаларда да кечкенәдән спортка карата уңай мөнәсәбәт, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләнә.
Әтиләре Алмаз кечкенәдән хоккей белән шөгыльләнә , бүгенге көндә Балтач “Сөт-май” комбинатының хоккей командасы капитаны. Команда Мари-турек, Саба, Балтач район масштабында үтә торган хоккей турнирларында призлы урыннар яулап торалар. Мари-Турек, Саба ябык боз сараенда үтүче турнирларда Балтач “Сөт-май” хоккей командасы беренче урында, Ципья зонасында ветеран хоккейчы Рафаэль Садыков исемендәге турнирларда 2010елда-I урын, 2011 елда-III урын, район җирлегендә үтүче Открытие, Закрытие турнирларда да команда призлы урыннарда тора. “Хезмәт” газетысы призына үтүче хоккей ярышларында Балтач “Сөт-май” хоккей командасы соңгы 3 елда беренчелекне кулдан төшерми. Кукмарада “Героев Космоса” призына үтүче хоккей ярышларында I урын, Норма җирлегендә “Интер” призына I урын һәм кубок белән бүләкләнделәр.
Зөһрәдә төрле спорт ярышларында актив катнаша һәм призлы урыннар яулый. Балтач җирлегендә үтүче “Лыжня России” чаңгы ярышында 2013, 2014 елларда призлы урыннарда.
Уллары Азамат кечкенәдән “Балтач” спорткомплексына “Теннис” секциясенә йөри, балалар бакчасында тәрбияләнүче Зәйнәп алардан бер дә калышмый: чаңгыда шуа, велосипедта йөри.
Районыбызда бу гаилә күпләргә үрнәк булырлык.